**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР №_19_**

Урыссу штп "_14_" декабрь 2017 ел

***2018 елга һәм 2019 – 2020 еллар план чорына Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты турында***

**1 статья**

2018 елга Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 25 815,5 мең сум күләмендә;

2) Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 25 815,5 мең сум күләмендә;

3) Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты кытлыгын 0 мең сум күләмендә.

2. 2019 елга һәм 2020 елга Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2019 елга Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 26 002,9 мең сум һәм 2020 елга 26 218,5 мең сум күләмендә;

2) 2019 елга Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 26 002,9 мең сум, шул исәптән 650,1 мең сум күләмендә расланган чыгымнар, һәм 2020 елга 26 218,5 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 1 310,9 мең сум күләмендә;

3) Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум һәм 2020 елга 0,0 мең сум күләмендә.

3. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты кытлыгын 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына финанслау чыганакларын әлеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

2018 елның 1 гыйнварына Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогының эчке бурычы 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында

муниципаль эчке бурычның 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында муниципаль эчке бурычның иң югары чиген 2020 елның 1 гыйнварына 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә.

4. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы муниципаль бурычының иң чик күләмен билгеләргә:

- 2018 елда - 0,0 мең сум күләмендә;
- 2019 елда - 0,0 мең сум күләмендә;
- 2020 елда - 0,0 мең сум күләмендә.

**3 статья**

Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетында 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге Карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

2018 елда һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорында Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы бюджетына Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе муниципаль унитар предприятиеләре табышының 2017, 2018 һәм 2019 еллар йомгаклары буенча салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган өлеше 2018, 2019 һәм 2020 елларның 1 июленә кадәр чиста табышның 10 проценты күләмендә күчерелә, дип билгеләргә.

**6 статья**

1. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**7 статья**

1. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре),

чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Бюджет ассигнованиеләрен 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетының 2018 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә 0,0 мең сум, 2019 елга 0,0 мең сум һәм 2020 елга 0,0 мең сум күләмендә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга.

**8 статья**

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга һәм физик затларга субсидияләр, шулай ук Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.5 статьясында каралган бюджетара трансфертлар әлеге Карар нигезендә Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бирелә.

**9 статья**

1.Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетында, Ютазы муниципаль районы бюджетыннан килә торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга, шул исәптән:

- 2018 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр 521,8 мең сум; 2019 елга 511,5 мең сумга, 2020 елга 508,2 мең сум күләмендә;
- 2018 елга хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр 482,6 мең сум, 2019 елга - 488,0 мең сум, 2020 елга - 512,3 мең сум күләмендә, әлеге Карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүленеп.

**10 статья**

1.Ютазы муниципаль районы бюджетына Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетыннан күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга, 2018 елга җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге чараларын тәэмин итүгә төзелгән килешүләр нигезендә 6 788,3 мең сум күләмендә, 2019 елга 6 788,3 мең сум күләмендә, 2020 елга 6 788,3 мең сум күләмендә, 2020 елга 6 788,3 мең сум күләмендә, әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетыннан Ютазы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга, 2018 елга торак-коммуналь хуҗалык чараларын тәэмин итүгә төзелгән килешүләр нигезендә 12 696,20 мең сум, 2019 елга 12 878,9 мең сум, 2020 елга 13 070,4 мең сум күләмендә әлеге Карарга 11 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетыннан Ютазы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен 2018 елга гомуми белем бирү чыгымнарын финанслашуга 4 634,7 мең сум күләмендә, 2019 елга 4 609,7 мең сум күләмендә, 2020 елга 4 604,8 мең сум күләмендә расларга.

4. 2018 елда һәм 2019 - 2020 елларның планлы чорында Ютазы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетыннан бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән күчерелә дип билгеләргә.

**11 статья**

1.Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы 2018 елда һәм 2019 һәм 2020 елларның планлы чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмалар хезмәткәрләре санын, шулай ук аларны тоту чыгымнарын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

**12 статья**

1. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен 2017 елда шушы муниципаль контрактларның шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә әлеге муниципаль районның Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетының калган акчалары 2018 елда тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы поселогы башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта җибәрелә.

**13 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

**14 статья**

Әлеге карарны Урыссу ш. т. п., Пушкин ур., 38 адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән һәм www.yutaza.tatar.ru Ютазы муниципаль

районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча игълан итәргә.

**15 статья**

Әлеге Карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**14 статья**

Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

*Урыссу шәһәр тибындагы*
*поселогы Башлыгы* -
*Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы рәисе*
*Р.М. Нуриев*